**Рус телендә урта гомуми белем бирү мәктәбенең рус төркемендә укучылар өчен татар теленнән үткәрелә торган муниципаль тур өчен олимпиада биремнәренең җаваплары 2021 -2022 уку елы, 4 нче сыйныф**

**Ответы олимпиадных заданий муниципального тура по татарскому языку для русскоязычных учащихся школ с обучением на русском языке 2021-2022 учебный год, 4 класс**

*Максимальный балл –* 63

***Письменная часть***

**Распредели слова по следующим категориям.** (*0,5 балла за каждый правильный ответ, максимальное количество – 7 баллов)*

Апа, нарат, өстәл, ипи, чалбар, Казан, тәнәфес, чәчәк, бабай, дәрес, Идел, күлмәк, ботка, урындык.

Гаилә АПА, БАБАЙ

Мәктәп ТӘНӘФЕС, ДӘРЕС

Ашамлык ИПИ, БОТКА

Кием ЧАЛБАР, КҮЛМӘК

Географик атама КАЗАН, ИДЕЛ

Үсемлек НАРАТ, ЧӘЧӘК

Йорт җиһазы ӨСТӘЛ, УРЫНДЫК

**2. Прочитайте утверждения. Подчеркните слово «әйе”, если вы согласны с утверждением, и “юк” если не согласны.***(Максимальное количество – 5 баллов)*

| | | |
|---|---|---|
| 1 | Сабантуй көз көне үткәрелә. | әйе / юк |
| 2 | Муса Җәлил – сугышта катнашкан герой-шагыйрь. | әйе / юк |
| 3 | Кышкы каникулда чаңгы шуалар. | әйе / юк |
| 4 | Җәй көне кар ява. | әйе / юк |
| 5 | Карга кара төстә була. | әйе / юк |

**3. Подчеркните лишнее слово в каждой строчке.***(Максимальное количество – 5 баллов)*

1) сары, кызыл, яшел, күңелле;
2) бара, йөгерә, укый, сикерә;
3) әти, әни, сыйныфташым, абый;
4) каен, чыршы, үлән, төлке;
5) акыллы, тәрбиясез, тыйнак, эшчән.

**4. Напишите существительные во множественном числе.**(*За каждый правильный ответ по 0,5 балла, максимальное количество – 3 балла)*

Дәрес - ДӘРЕСЛӘР

Кош - КОШЛАР

Урман - УРМАННАР

Төн - ТӨННӘР

Китап - КИТАПЛАР

Сан - САННАР

**5. Составьте предложение из предлагаемых слов.***(Максимальное количество – 9 баллов)*

1) Мәктәптә, куйдык, кичә, концерт, без.

БЕЗ КИЧӘ МӘКТӘПТӘ КОНЦЕРТ КУЙДЫК.

2) Мине, сыйлый, тәмле, белән, өчпочмаклар, әбием.

ӘБИЕМ МИНЕ ТӘМЛЕ ӨЧПОЧМАКЛАР БЕЛӘН СЫЙЛЫЙ.

3) ничә, сиңа, тулды, яшь?

СИҢА НИЧӘ ЯШЬ ТУЛДЫ?

**6. Переведите следующие предложения на татарский язык.** (*За каждый правильный ответ по три балла, максимальное количество – 9 баллов)*

1) Я иду в школу.

МИН МӘКТӘПКӘ БАРАМ.

2) Я учусь в четвёртом классе.

МИН ДҮРТЕНЧЕ СЫЙНЫФТА УКЫЙМ.

3) Я люблю свою семью.

МИН ГАИЛӘМНЕ ЯРАТАМ.

**7. Прочитайте текст и отметьте знаком «+» предложения, соответствующие содержанию текста, а знаком «-» неверные**. (*За каждый правильный ответ по 2 балла. Максимальное количество – 10 баллов)*

Казанда Тукай музее 1896 нчы елда ачылган. Ул бик матур бинада урнашкан.

Беренче залда шагыйрьнең бала чагы турында сөйләнә. Кушлавыч авылының зур фоторәсеме бар. Габдулла Тукай шушы авылда туган.

Фоторәсемнәрдә юллар, юллар... Алар ятим баланы әле Сасна, әле Өчиле авылына, әле Казанга, әле Кырлайга, тагын Өчилегә, аннан Уральск шәһәренә алып киткәннәр.

Шул ук юллар Тукайны мәңгелек данга алып килгән. Шагыйрь халкы өчен язган, халкы өчен яшәгән.

Тукайның шәхси әйберләре музейда юк диярлек. Ә халыкка калдырган әсәрләре бик күп. Аларның тиражы 7 миллионнан артык. Тукайның шигырьләре чит телләрдә дә басылган. 100 дән артык әсәренә музыка язылган.

1. Тукайның шәхси әйберләре музейда бик күп. -
2. Габдулла Тукай Кырлай авылында туган. -
3. Тукай кечкенәдән әти-әнисез кала. +
4. Музейда юллар төшерелгән фоторәсемнәр бар. +
5. Габдулла Тукай бик күп әсәрләр язган. +

**8. Озаглавьте рисунок** *(5 баллов)*, **напишите слова (10 слов), которые относятся к рисунку.** *(По одному баллу за каждое слово, максимальное количество – 15 баллов.)*



**Рус телендә урта гомуми белем бирү мәктәбенең рус төркемендә укучылар өчен татар теленнән үткәрелә торган муниципаль туры өчен олимпиада биремнәренең җаваплары 2021-2022 уку елы, 5 нче сыйныф**

**Ответы олимпиадных заданий муниципального тура по татарскому языку для русскоязычных учащихся школ с обучением на русском языке 2021-2022 учебный год, 5 класс**

Максимальный балл – 80

1. **Напишите антонимы к словам.** (*Максимальное количество – 6 баллов)*

1) озын –КЫСКА
2) төн –КӨН
3) яшь – КАРТ
4) китә - КИЛӘ
5) җавап - СОРАУ
6) салкын - ҖЫЛЫ

**2. Посмотрите на рисунок. Напишите слова, обозначающие части тела человека.** (*За каждое* слово *– 1 балл, максимальное количество – 10 баллов)*

| | |
|---|---|
|  | БАШ, КҮЗ<br>…________________________________<br>________________________________<br>________________________________<br>________________________________<br>________________________________<br>________________________________<br>________________________________<br>________________________________<br>________________________________ |

3.**Найдите перевод пословиц.***(Максимальное количество – 10 баллов)*

| | |
|---|---|
| 1) Кем эшләми, шул ашамый. | А) Больше слушай, меньше говори. |
| 2) Аз сөйлә, күп тыңла. | Б) Волка кормят ноги. |
| 3) Китап – кешенең дусты. | В) Прочитал новую книгу – встретился с другом. |
| 4) Бүрене аяклары ашата. | Г) Книга – друг человека. |
| 5) Яңа китапны укыдың – үзеңә дус таптың. | Д) Кто не работает, тот не ест. |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| | | | | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| Д | А | Г | Б | В |

4**. Подчеркните правильный ответ на вопрос**. (*Максимальное количество – 6 баллов)*

1) Бүген дүшәмбеме? – Әйе, бүген кар яуды. / Әйе, бүген атнаның беренче көне./ Әйе, бүген 22 нче декабрь.
2) Син иртәгә китапханәгә киләсеңме? – Әйе, мин иртәгә кибеткә киләм. / Китапханә иртәнге тугызда ачыла. / – Әйе, мин иртәгә китапханәгә киләм.
3) Якшәмбе көнне син нишләдең? – Атна ахырында мин кунакка бардым. / Атна уртасында мин концертка бардым. / Атна башында мин спорт секциясенә бардым.

**5.Впишите в предложение подходящее по смыслу слово**. (*Максимальное количество – 10баллов)*

1) Мин ҖӘЙГЕ (кышкы, җәйге) каникулда су коенырга бардым.
2) КӨЗ (көз, яз, җәй) җиткәч, яфраклар коела башлый.
3) Маратның күзләре яхшыКҮРӘ (ишетә, күрә).
4) Китап дәфтәргә караганда КАЛЫНРАК (югарак, калынрак).
5) Бер айда ничә КӨН (көн, ел)?

**6. Найдите правильные варианты окончания предложений. Впишите ответы в таблицу.**(*Максимальное количество* – 10*баллов)*

| | |
|---|---|
| 1) Мин укытучыбызны | А) кунакка бардык. |
| 2) Миңа бик матур | Б) бәйрәм белән котладым. |
| 3) Кичә без әбиләргә | В) күңелле бәйрәм. |

| | |
|---|---|
| 4) Туган көн – | Г) ашыгыз тәмле булсын! |
| 5) Кызлар, малайлар, | Д) чәчәкләр бүләк иттеләр. |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| Б | Д | А | В | Г |

**7. Прочитайте текст и вставьте пропущенные окончания.**(*Максимальное количество –*6 *баллов)*

Сабантуй –зур бәйрәм. Аңа алдан әзерләнәләр.

Башта малайлар, егетләр СабантуйГА бүләк  җыялар. Алар арасында гармунчы да була.  Бүләк җыючыларНЫ һәр өйДӘ көтәләр.  Хуҗалар матур сөлгеләр, яулыклар, кулъяулыклар бирәләр. Бүләк җыючылар рәхмәт әйтәләр, бииләр, җырлыйлар.

Сабантуй зур мәйданДА була. Ярышлар башлана. Иң беренче ат чабышы була. 8-12 яшьлек малайлар атларГА  атланалар.Алар 8 километр ераклыкка, старт урынына китәләр. Сигнал буенча мәйданГА чабалар.

Мәйдан уртасында көрәш бара. Аны кечкенә малайлар башлый. Аннан соң зуррак малайлар, егетләр, ирләр көрәшә. Җиңүче Сабантуй батыры була.

Менә шундый күңелле бәйрәм ул Сабантуй!

**8. Выберите наиболее подходящую для текста пословицу.** *(Максимальное количество  – 5 баллов)*

☐Сәламәтлек – зур байлык.

☐Һәр илнең үз йоласы.

☐Талант эшне ярата.

☐Эш кешене кеше итәр.

**9. Посмотрите на рисунок. Озаглавьте рисунок** *(5 баллов)* **и составьте по рисунку 6 словосочетаний** ***(2 балла за каждое словосочетание. М****аксимальное количество – 17* ***баллов.)***



***НАПРИМЕР, КЫШКЫ КӨН,***

______________________________________________

______________________________________________

______________________________________________

______________________________________________

______________________________________________

______________________________________________

**укучылар өчен татар теленнән үткәрелә торган муниципаль тур олимпиада биремнәренең җаваплары**
**2021/2022 уку елы, 6 нчы сыйныф**

**Ответы олимпиадных заданий муниципального тура**
**по татарскому языку для русскоязычных учащихся**
**школ с обучением на русском языке**
**2021/2022 учебный год, 6 класс**

*Максимальное количество баллов – 80*

**1. Озаглавьте рисунок (3 балла) и напишите 5 предложений (за каждое верное предложение – 4 балла. Максимальный балл -23)**

**2. Прочитайте предложения, исправьте грамматические и речевые ошибки. Напишите правильный вариант (максимальный балл – 4)**

*1)Чүпрәк битлекне ике сәгать саен алыштырырга кирәк.*

*2) Юешләнгән очракта аны шунда ук салып кую хәерле.*

*3) Чүпрәк маскаларны кесәгә салып куя күрмәгез: аннан вируслар ачкычларга, телефонга күчә ала.*

*4) Табиб мондый битлекләрне пакетка салып өйгә алып кайтырга киңәш итә.*

**3. Прочитайте загадку. О чём эта загадка? *(максимальный балл – 3)*.**

*Борчак*

**4. Расставьте реплики в нужном порядке (укажите последовательность в цифрах), чтобы получился диалог *(максимальный балл - 11)*.**

*3, 5, 8, 6, 10, 7, 11, 1, 4, 9, 2*

**5. В каждой строчке зачеркните “четвертое лишнее слово” *(максимальный балл – 4)*.**

*1) сыерчык, песнәк, болын, тургай*

*2) мәрхәмәтле, сaран, эшлекле, хөрмәтле*

*3) авылдаш, якташ, сыйныфташ, ватан*

*4) көнбагыш, карабодай, өрәңге, борчак*

**6. Дополните предложение подходящим по смыслу словом *(максимальный балл – 5)*.**

*1) Декабрь ае кыш башлануны хәбәр итә.*

*2) Урман да яшел тунын салган, карасу төскә кергән.*

*3) Кышын кояш сирәк күренә, әмма ул барыбер җылытмый.*

*4) Кышын кошлар һәм хайваннарга азык табу авырлаша.*

*5) Шуңа күрә алар бу чорда тирән йокыга талалар.*

**7. Переведите предложения *(максимальный балл – 10)*.**

*1) Әгәр сез кагыйдәне ятласагыз/өйрәнсәгез, тестны да яхшы язарсыз.*

*2) Бакчаның сул ягында алмагач үсә.*

*3) Безнең республикада йөздән артык милләт вәкилләре яши.*

*4) Кичә мин мәктәптә таныш булмаган кешене күрдем.*

*5) Ул беркайчан да укырга/ укуга соңга калмый.*

**8. “Соберите пословицы”, соединив цифры с буквами *(максимальный балл – 5)*.**

***1) д; 2) а; 3) в; 4) б; 5) г***

**9. Поздравьте друга (подругу) с днем рождения, пожелайте здоровья, счастья, успехов, исполнения желаний *(за каждое верное предложение – 3 балла, максимальное количество баллов – 15)*.**

**Рус телендә урта гомуми белем бирү мәктәбенең рус төркемендә укучылар өчен татар теленнән үткәрелә торган муниципаль тур олимпиада биремнәренең җаваплары**

**2021/2022 уку елы, 7 нчы сыйныф**

**Ответы олимпиадных заданий муниципального тура**
**по татарскому языку для русскоязычных учащихся**
**школ с обучением на русском языке**
**2021-2022учебный год, 7 класс**

*Максимальное количество баллов – 82*

**1. Озаглавь рисунок (3 балла) и напишите 5 предложений (за каждое верное предложение - 4 балла. Максимальный балл – 23)**



**2. Прочитайте предложения, исправьте грамматические и речевые ошибки. Напишите правильный вариант** *(максимальный балл – 5)*

*1) Коронавирус белән авырган вакытта ук, табиблар күпләп С витаминын эчәргә кушалар.*

*2) Терелгәннән соң да, белгечләр <u>күпләп</u> лимон, апельсин, мандарин ашауны хуплый.*

*3) Цитрусларны теләсә кайсы төрдә куллану яхшы, ягъни яңа гына <u>чыгарылган</u> сок, смузи ясап эчүнең дә файдасы зур булачак.*

*4) Ә менә лимонны <u>кабыгы</u> белән бергә ашарга киңәш ителә.*

*5) Тагын табиблар көн <u>саен</u> 5 порциядән дә ким булмаган яшелчә, җиләк – җимеш, салат яфраклары һәм яшел тәмләткечләр куллану турында әйтә.*

**3. Прочитайте текст, найдите и напишите пропущенное слово** *(максимальный балл – 4).*

***<u>Ат</u>***

**4. Расставьте реплики в нужном порядке (укажите последовательность в цифрах), чтобы получился диалог** *(максимальный балл - 10).*

*4, 9, 7, 1, 10, 5, 8, 3, 6, 2*

**5. Вставьте пропущенные компоненты фразеологизмов *(максимальный балл – 7)*.**

*1) <u>алтын</u> куллы*

*2) ике <u>ут</u> арасында*

*3) чебеннән <u>фил</u> ясау*

*4) энә белән <u>җеп</u> кебек*

*5) <u>баш</u> әйләнү*

*6) <u>ике</u> куян артыннан куу*

*7) ике <u>тамчы</u> су кебек*

**6. Подберите антонимы к именам прилагательным, учитывая их лексическое значение. *(максимальный балл – 5)*.**

*язма сөйләм – телдән сөйләм*

*кыйммәт күлмәк – арзан күлмәк*

*шатлыклы көн – кайгылы көн*

*ярлы кеше – баш кеше*

*эчке матурлык – тышкы матурлык*

**7. Переводите предложения *(максимальный балл – 8)*.**

*1) Мин белдерү күрдем, сез җомга чыгыш ясыйсыз икән.*

*2) Мәктәп китапханәсендә татар китаплары һәм сүзлекләре аз.*

*3) Син бик тә тыйнак икәнсең.*

*4) Сезгә бу күлмәк бик килешә.*

**8. Соберите пословицы, соединив цифры с буквами *(максимальный балл – 5)*.**

*1) д; 2) в; 3) г; 4) б; 5) а.*

**9. Напишите какую музыку вы любите *(за каждое верное предложение – 3, максимальный балл – 15)*.**

**Рус телендә урта гомуми белем бирү мәктәбенең рус төркемендә укучылар өчен татар теленнән үткәрелә торган муниципаль тур олимпиада биремнәренең җаваплары 2021-2022 уку елы, 8 нче сыйныф**

**Ответы олимпиадных заданий муниципального тура по татарскому языку для русскоязычных учащихся школ с обучением на русском языке 2021-2022учебный год, 8 класс**

*Максималь балл – 71*

**1. Озаглавьте картину (5 баллов). Составьте 7 словосочетаний по картине (по 2 балла = 14 баллов). Макс. 19 баллов**



**Ачкыч:** “Күңелле ял”/ “Футбол уены” / “Сәламәт гаилә”.
Җәйге көн, күңелле каникул, тату гаилә, футбол уйнау, гол кертү, ике малай, футбол кыры.

**2. Прочитайте текст. Исходя из содержания текста, поставьте рядом с каждым предложением отметку “+” или “-“. (8 баллов)**

Футболны турыпочмаклы мәйданда уйныйлар. Аның уртасына капма-каршы капка куела.Уенның максаты — көндәшләр капкасына туп кертү. Һәр командада унбер уенчы була. Уен кырык бишәр минутлык ике таймнан тора һәм туксан минут дәвам итә. Алар арасында ун минутлык тәнәфес була. Капкачыдан башка беркемгә дә тупка кул белән тияргә ярамый.Футбол — күмәк уен, шуңа күрә һәр уенчы үз хәрәкәтен командадагы башка иптәшләренең хәрәкәте белән килешеп башкарырга тиеш.

1) Футболны өчпочмаклы мәйданда уйныйлар. -
2) Мәйдан уртасына капма-каршы капка куела.+
3) Көндәшләр капкасына туп кертү уенның максаты булып тора. +
4) Һәр командада унике уенчы була.-
5) Уен 45әр минутлык 2 таймнан тора һәм 90 дәвам итә. +
6) Алар арасында ике тапкыр ун минутлык тәнәфес була.-
7) Тупка бер уенчы да кул белән тияргә тиеш түгел.-
8) Футбол күмәк уен булу сәбәпле, һәр уенчы үз хәрәкәтен командадагы башка иптәшләренең хәрәкәте белән килешеп башкарырга тиеш.+

**3. В тексте пропущено каждое пятое слово. Заполните пробелы с подходящими по смыслу словами (самостоятельными или служебными). (12 баллов, по 2 балла за каждый правильный ответ)**

Кайбер кешеләр беркайчан да ____________________ белән шөгыльлән-миләр. Кеше организмы ___________________ зыянлы әйберләр кулланучылар да ______________. Кайберәүләр күп ашыйлар. Андый __________________ еш авырыйлар. Без гаиләбез ____________ спорт

яратабыз. Футбол уйнау________________ ныгыта.

**Ачкыч:** спорт (физкультура), өчен, күп (бар), кешеләр, белән, сәламәтлекне.

**4. Укажите пословицу сантонимами. (1 балл)**
1) Батырлыкта матурлык.
2) Куркакның кулы кыска.
**3) Кыю бер үләр, куркак мең үләр.**
4) Карама яшенә, кара эшенә.

**5. В какой последовательности необходимо поставить выражения, чтобы получилась пословица? (4 балла)**
А) төсенә карап
Ә) эшенә карап
Б) кошның матурлыгы
В) кешенең матурлыгы
1) Ә, Б, В, А
2) Б, А, В, Ә
3) А, В, Б, Ә
4) Б, Ә, А, В
Җавап:_______________________________
**Ачкыч: Б, А, В, Ә**

**6. Укажите ряд, состящий только из местоимений. (1 балл)**
1) мөмкин, шул, беркем, бу
**2) алай, анда, безнеке, бернинди**
3) ихтимал, әкрен, әллә кем, ничек
4) алай-болай, ник, әйе, зур

**7. Выполните коммуникативные задания. (10 баллов, по 2 балла за каждый правильный ответ)**
Сообщи другу:
-в здоровом теле здоровый дух;
***Сәламәт тәндә сәламәт рух.***
-чтобы быть здоровым, надо отказаться от вредных привычек;
***Сәламәт булу өчен зарарлы гадәтләрдән баш тартырга кирәк.***
-очень полезно употреблять витаминные продукты;
***Витаминлы ризыклар ашау бик файдалы.***
-ежедневная прогулка на свежем воздухе или бег укрепляют организм человека;
***Көн саен саф һавада йөрү яки йөгерү кеше организмын ныгыта.***
- позитивное мышление улучшает физическое и психологическое состояние человека;

***Позитив фикерләү кешенең физик һәм психологик хәлен яхшырта.***

8. **По тексту составьте диалог на татарском языке (8 реплик). (16 баллов, по 2 балла за каждое правильное предложение).**

Сәламәтлекне саклау өчен, спиртлы эчемлекләр эчмәү, тәмәке тартмау – иң беренче шарт. Галимнәр әйтүенчә, бер тәмәке гомерне җиде минутка кыскарта. Спиртлы эчемлекләр куллану нәрсәгә китерә? Спиртлы эчемлекләр куллану физик һәм психик авырулар китереп чыгара.

**Ачкыч:**

- Сәламәлекне саклау өчен нишләргә кирәк?
- Сәламәтлекне саклау өчен, спиртлы эчемлекләр эчмәү, тәмәке тартмау – иң беренче шарт.
- Тәмәке тарту зарарлымы?
- Әйе, тәмәке тарту зарарлы: бер тәмәке гомерне җиде минутка кыскарта.
- Спиртлы эчемлекләр куллану нәрсәгә китерә?
- Спиртлы эчемлекләр куллану физик һәм психик авырулар китереп чыгара.
- Синең зарарлы гадәтләрең бармы?
- Юк, әлбәттә.

**Рус телендә урта гомуми белем бирү мәктәбенең рус төркемендә укучылар өчен татар теленнән үткәрелә торган муниципаль тур олимпиада биремнәренең җаваплары 2021-2022 уку елы, 9 нчы сыйныф**

**Ответы олимпиадных заданий муниципального тура по татарскому языку для русскоязычных учащихся школ с обучением на русском языке 2021-2022учебный год, 9 класс**

*Максимальный балл –80*

**2. Озаглавьте картину (5 баллов). Составьте 7 словосочетаний по картине (по 2 балла = 14 баллов). Макс. 19 баллов**



**Ачкыч:** “Дәрестән соң”/ “Дуслар” / “Паркта очрашу”.
Җәйге көн, ике кыз, өч егет, китап уку, телефон карау, музыка тыңлау, күңелле очрашу.

3. **Прочитайте текст. Исходя из содержания текста, поставьте рядом с каждым предложением отметку «+ » или “-“. (8 баллов)**

Хезмәт темасы фольклорда күптөрле яктыртыла. Халык иҗаты әсәрләрендә эшнең яхшы сыйфатлы булуы гаять югары бәяләнә. Ә иң ачы һәм үткен тәнкыйть сүзләре эшне аннан-моннан гына башкаручыларга каршы юнәлтелә.«Яхшы эш үз-үзен мактый», — ди халык. Ә түбән сыйфатлы эш ахыр чиктә барыбер фаш ителә, аны, өстәмә көч куеп, кабаттан эшләргә, төзәтергә туры килә. «Аннан-моннан эшләсәң, яңадан эшләрсең», «Кабат эшләнгән эш сабак булыр» кебек мәкальләр мәсьәләнең бу ягын да искәртеп үтәләр.Югары сыйфатка ирешү өчен, кеше үз эшен, үз һөнәрен яхшы белергә, аның чын остасы булырга, хезмәтне яратып, күңел биреп һәм җаваплылык тоеп башкарырга тиеш.

1) Хезмәт темасы фольклорда күптөрле яктыртыла. +
2) Халык иҗаты әсәрләрендә югары сыйфатлы хезмәтбәяләнеп бетми.-
3) Эшне аннан-моннан башкаручыларнытәнкыйтьлиләр. +
4) Халыкның «Яхшы эшләгән кеше үз-үзен мактый» дигән мәкале бар.-
5) Түбән сыйфатлы эшне өстәмә көч куеп, кабаттан эшләргә, төзәтергә туры килә. +
6) Эшне аннан-моннан гына эшлә, яңадан эшләмә.-
7) Кеше үз эшен, үз һөнәрен яхшы белергә, аның чын остасы булырга тиеш.+
8) Хезмәтне яратып, күңел биреп һәм җаваплылык тоеп башкарырган кеше югары сыйфатка ирешә.+

**3. Укажите пословицу безантонимов. (1 балл)**
1) **Матурлык туйда кирәк, эшчәнлек көн дә кирәк.**
2) Эш кешене төзәтә, ялкаулык - боза.
3) Башланган эш - беткән эш.
4) Тырышлык - зурлык, ялкаулык - хурлык.

**4. Укажите продолжение пословицы. (1 балл)**

*Кул белән эшлисең, ....*
1) аяк белән йөрисең.
**2) башың белән җавап бирәсең.**
3) күзләрең курка.
4) күңелең белән борчыласың.

**5. В какой последовательности необходимо поставить выражения, чтобы получилось предложение? (4 балла)**
А) акыл табылмас
Ә) акыл белән
Б) алтын табылса
В) алтын белән
**1) Ә, Б, В, А** 2) Б, А, В, Ә 3) А, В, Б, Ә 4) Б, Ә, А, В

**6. Укажите предложение с условным наклонением глагола. (1 балл)**
1) Елның кайсы гына вакыты булмасын, урман безне үзенә тарта.
**2)Илең турында уйласаң, гомерең озын була. (Ф. Кәрим)**
3)Укылып бетмәгән китап — яшәлеп бетмәгән гомер.
4)Урманында кып-кызыл кура җиләк тә җир җиләк, Күз ачып йомганчы, һичшиксез, җыярсың бер чиләк.

**7. В тексте пропущено каждое пятое слово. Заполните пробелы с подходящими по смыслу словами (самостоятельными или служебными). (18 баллов, по 2 балла за каждый правильный ответ)**

Алма бакчасына ябалак ияләләште. _______________ тычканнарны аулый башлады. Төн________________ тычкан тоткан ябалак көндез ____________________кала. Кышкы салкыннарда Кәрим ___________________төрле тәм-том белән сыйлый. _____________________көне ябалак каядыр китеп _____________________. Кәрим аны бик сагына. __________________ бу аерылу озакка бармый. ____________________күз җиткәч, ябалак тагын _______________килә, тычканнарга көн күрсәтми.

**Ачкыч:** ул, буе, бакчада, аны, җәй, югала, ләкин, яңгырлы (сары, салкын), бакчага.

**8. Выполните коммуникативные задания. (12 баллов: по 2 балла за каждое правильное предложение)**
Сообщи другу:
- важно соблюдать требования повседневной гигиены: чистить зубы, мыться, носить чистую одежду, проветривать комнату.
***Көндәлек гигиена таләпләрен үтәү әһәмиятле: тешләрне чистартырга, юыныырга, чиста киенеп йөрергә, бүлмәне җилләтергә кирәк.***
- позитивные мысли способствуют созданию гормона радости.

***Позитив уйлар шатлык гормоны булдыруга ярдәм итә.***
Спроси друга:
- если бы он был кинорежиссером, какой бы фильм снял?
***Син кинорежиссер булсаң, нинди фильм төшерер идең?***
- если бы он был писателем, о чем бы написал?
***Язучы булсаң, нәрсә турында язар идең?***
Посоветуй другу:
- бегать по утрам;
***Дустым, иртә белән йөгер! (йөгерергә кирәк).***
- один раз в неделю посещать фитнес-центр.
***Дустым, атнага бер тапкыр фитнес-үзәккә бар!***

9. **По тексту составьте диалог на татарском языке (8 реплик). (16 баллов, по 2 балла за каждое правильное предложение).**

Татар телендә беренче китап 1612 нче елда Лейпцигта чыккан. 1800 нче елда Казанда беренче типография ачылган. Димәк, татар китабы революциягә чаклы 200 елга якын юл үткән. Шушы вакыт эчендә 11 мең чамасы татар китабы басылып чыккан, аларның гомуми тиражы 50 миллион данәдән узып китә.Татар телендә чыккан китапларның саны, аларның эчтәлеге белән танышкач, татарларның элек-электән укымышлы халык булуына ышанабыз.

**Ачкыч:**

- Татар телендә беренче китап кайчан һәм кайда чыккан?
- Татар телендә беренче китап 1612 нче елда Лейпцигта чыккан.
- Казанда беренче типография кайчан ачылган?
- Казанда беренче типография 1800 нче елда ачылган.
- Димәк, татар китабы революциягә чаклы 200 елга якын юл үткән?
- Әйе, шушы вакыт эчендә 11 мең чамасы татар китабы басылып чыккан, аларның гомуми тиражы 50 миллион данәдән узып китә.
- Татар телендә чыккан китапларның саны, аларның эчтәлеге белән танышкач, нинди фикергә киләбез?
- Татарларныңэлек-электән укымышлы халыкбулган.

**Рус телендә урта гомуми белем бирү мәктәбенең рус төркемендә укучылар өчен татар теленнән үткәрелә торган муниципаль туры өчен олимпиада биремнәренең җаваплары 2021-2022 уку елы, 10 нчы сыйныф**

**Ответы олимпиадных заданий муниципального тура по татарскому языку для русскоязычных учащихся школ с обучением на русском языке 2021-2022 учебный год, 10 класс**

*Максимальный балл – 117*

**4. Озаглавьте картину (5 баллов).** – ОНЫКЛАР КИЛДЕ// ИГЕЛЕК
**Какая пословица раскрывает суть картины (5 баллов):**

1) Ачы булса да дөресен әйт!
2) Дусны шәм яндырып эзлә.
3) Бер рәхмәт мең бәладән коткарыр.
4) Кеше малы белән мактанма.

**Составьте 7 словосочетаний по картине (по 2 балла = 14 баллов). Макс. б. - 24**



Например: пандемия чоры, кайгыртучан оныклар, олы жанлы, шат йөзләр, рәхмәт хисе, файдалы ризыклар, көтеп алу һ.б.

**2. Прочитайте текст. Отметьте, о ком приведенные в таблице фразы (9 баллов). Приведите словосочетания, характеризующие виды дружбы, например: халыклар дуслыгы (по 1 баллу за каждое сочетание- до 6 баллов). Макс. б. -15 .**

Дамирның ике дусты бар: Руслан һәм Әмир. Аларны көлеп “өч мушкетер” дип йөртәләр иде. Алар беренче сыйныфта дуслаштылар, чөнки уртак яклары күп иде: бергә мәктәпкә йөриләр, бергә футбол уйныйлар, бер команда өчен җан аталар. Ләкин 8 нче сыйныфта алар аерылдылар. Дамир аңлады: кемне дә булса сайларга кирәк иде. Ләкин кемне сайларга?!

Руслан белән һәрвакыт кызык, җиңел. Ул еш кына өенә кунакка

чакыра. Руслан һәрвакыт акчалы, киемнәре дә модалы. Алар, хәтта, дәрес калдырып, бергә компьютер уеннары уйныйлар.

Әмир белән Дамир сирәк очраша. Әмир әле дә йөзүгә йөри, ә Дамир инде спортны ташлады. Әмир һаман шул спорт турында гына сөйләшә. Аның уйлары бары киләчәк тормыш турында. Ә иң мөһиме – Дамирга еш әйтә: спорт белән шөгыльләнергә кирәк, дәресләрне калдырырга ярамый, дуслар сайлый белмисең.

| | Руслан | Әмир |
|---|---|---|
| Ул дустына яхшылык тели, шуңа күрә тәнкыйтьли. | | + |
| Ул сәбәпсез дәрес калдыра. | + | |
| Аның үз фикере, үз хыяллары бар, ул мөстәкыйль кеше. | | + |
| Ул начар дус, чөнки дусты белән бары күңел ача. | + | |
| Аның киемнәре заманча, модалы. | + | |
| Ул әти – әнисе акчасын туздыра. | + | |
| Аның уйлары бары киләчәк тормыш турында. | | + |
| Ул дуслары белән сирәк очраша, чөнки вакыты юк. | | + |
| Ул спорт белән шөгыльләнә. | | + |

Дуслык: <u>мәсәлән, халыклар дуслыгы, малайлар дуслыгы, илләр дуслыгы, чын дуслык, милләтләр дуслыгы һ.б.</u>

**3. Верните пропущенные слова в текст (по 1 баллу). Макс. – 9 б.**

1. Әсгать Галимҗановны <u>БӨТЕН</u> Казан белә. 2.Ул гомере <u>БУЕ</u> фаҗига кичергән кешеләргә, <u>ЯТИМ</u> балаларга, картларга һәм инвалидларга булыша. 3. Балалар йортларына сиксәннән <u>АРТЫК</u>

автобус, йөзләгән телевизор САТЫП алып бирә. 4. Бу кешегә ӘЛЕ үзе исән вакытта ук Казанның НӘКЪ үзәгендә Кремль янында һәйкәл КУЕЛА. 5. Әсгать Галимҗанов ИГЕЛЕК эшләү үрнәге булып тора.

**Слова: ятим, артык, нәкъ, куела, игелек, бөтен, әле, сатып, буе.**

**4. Из слов составьте предложения и запишите в таблицу. (10 баллов)**
**1)**малай, икенче, чыкты, белән, ягына, эте, урамның
**2**) кирәк, ял, тырышып, өчен, итәр, яхшы, эшләргә.
**3)**урын, кеше, хатын-кызларга, тиеш, өлкәннәргә, егет, бирергә, тиеш.
**4**) без, җыярга, бик, урманда, яратыбыз, җиләк.
**5)**әнисе, чәчәк, Гүзәлнең, бәйләме, кайтты, беркөнне, тотып, матур.

| **№** | **Предложения** | **Баллы** (макс.) ( 10 ) | **Сумма** (фактич.) ( ) |
|---|---|---|---|
| **1.** | Малай эте белән урамның икенче ягына чыкты. | 2 | |
| **2.** | Яхшы ял итәр өчен тырышып эшләргә кирәк. | 2 | |
| **3.** | Егет кеше хатын-кызларга, өлкәннәргә урын бирергә тиеш. | 2 | |
| **4.** | Без урманда җиләк җыярга бик яратабыз. | 2 | |
| **5.** | Гүзәлнең әнисе беркөнне матур чәчәк бәйләме белән кайтты. | 2 | |

**5. Какие числа спрятаны в следующих словах? (по 1 баллу) Макс. -7 б.**
фикер – ике
көчек – өч
кунак – ун
алтын – алты
бишек - биш
бертуган- бер
меңъяфрак - мең

**6. В какой последовательности необходимо поставить выражения, чтобы получилась пословица? (4 балла)**

А) эзләгән корт
Ә) эшләгән кеше
Б) бал табар
В) мал табар
1) Ә, Б, В, А
2) Б, А, В, Ә
3) А, Б, Ә, В
4) Б, Ә, А, В
Җавап:______________________________

**7. В каком ряду расположены слова, характеризующие занятия спортом. (4 балла)**

1) укырга, ятларга, утырырга, аңларга
2) ярышырга, йөгерергә, йөзергә, шөгыльләнергә
3) язарга, йокларга, карарга, кызыксынырга
4) сорашырга, йөрергә, шуарга, атларга

**8 . Переведите на татарский язык и запишите (по 3 б., макс. – 18 б.).**

1). Один человек со своей женой и детьми гулял в центре Москвы. 2) Он хотел поехать домой на такси. 3). Он сказал шоферу свой адрес и спросил, сколько будет стоит поездка. 4) «Восемьсот рублей за вас и вашу жену. Детей я довезу бесплатно», - ответил таксист и улыбнулся. 5). Тогда отец сказал детям: «Садитесь в такси, дети! 6) Дядя везет вас до дома, а мы с мамой поедем на метро».

| № | **Предложения** | **Баллы** (макс.) ( 18) | **Сумма** (фактич.) ( ) |
|---|---|---|---|
| 1. | Бер кеше үзенең хатыны һәм балалары белән Мәскәү үзәгендә йөргән. | | |
| 2. | Ул өенә такси белән кайтырга теләгән. | | |
| 3. | Ул шоферга үзенең адресын әйткән һәм бәясе ничә сум булуын сораган. | | |
| 4. | “Хатыныгыз белән сезнең өчен сигез йөз сум. Балаларны мин бушка алып барам (кайтарып | | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | куям)”, дигән таксист һәм елмайган. | | |
| 5. | Шунда әтиләре балаларына болай дигән: “Балалар, таксига утырыгыз! Абый сезне өйгә кайтарып куя, ә без, әниегез белән, метрода кайтабыз”. | | |

**9. Выполните коммуникативные задания. (10 баллов, по 2 балла за каждый правильный ответ)**

Скажи родителям (маме , папе):

- что ты беспокоишься за их здоровье;
- Әтием, әнием, мин сезнең сәламәтлегегез өчен борчылам.
- что им необходимо ехать отдыхать;
- ... , сезгә ял итәргә кирәк;

- что очень полезно употреблять витаминные продукты;

- ..., витаминлы ризыклар ашау файдалы;

- что перед сном нужно гулять на свежем воздухе;

- ..., йоклар алдыннан саф һавада йөрергә кирәк;

- что ты очень благодарен (на) им и очень хочешь, чтобы они были здоровые

- ..., мин сезгә бик рәхмәтле һәм бик нык сезнең сәламәт булуыгызны телим.

10. Допишите продолжение текста (6-8 предложений) **(16 баллов, по 2 балла за каждое правильное предложение).**

Без туганнарыбызга, дусларыбызга бүләкләр бирәбез. Бик матур гадәт. ...

________________________________________________________________________
________________________________________________________________________
________________________________________________________________________
________________________________________________________________________
________________________________________________________________________
________________________________________________________________________
________________________________________________________________________
________________________________________________________________________
______________

## Рус телендә урта гомуми белем бирү мәктәбенең рус төркемендә укучылар өчен татар теленнән үткәрелә торган муниципаль туры өчен олимпиада биремнәренең җаваплары 2021-2022 уку елы, 11 нче сыйныф

## Ответы олимпиадных заданий муниципального тура по татарскому языку для русскоязычных учащихся школ с обучением на русском языке 2021-2022 учебный год, 11 класс

*Максимальный балл – 131*

**5. Озаглавьте картину (5 баллов). Составьте 5 предложений по картине (по 2 балла = 10 баллов). Макс. 15 баллов**



Табигатьне саклыйк/ Сулыкларны пычратмыйк/ Экологик мәсьәләләр игътибар сорый.

Җир шарына экологик куркыныч яный. Кешеләр җир-суларны пычрата, андагы тереклекне куркыныч астына куя. Табигать кешеләрнең ярдәменә мохтаҗ... һ.б.

**6. Прочитайте текст. Переведите слова, приведенные после**

**текста. Используя эти слова, допишите пропущенную часть текста (5-6 предложений)**

**за каждое слово по 1 баллу, макс.б. - 8**

**за каждое предл. по 3 балла, макс. б. – 18 = 26 б.**

Һәркем белә, сусыз яшәү мөмкин түгел. Кеше ашамыйча атналар буе тора ала, әмма сусыз бирничә көнгә дә түзә алмый. Әгәр кеше тәнендәге суның уннан бер өлеше кимесә дә, аның хәле начарлана. Менә суда нинди көч бар! Җир шарында эчәргә яраклы су запасы күп түгел. Кешеләр тарафыннан көн саен күп күләмдә су тотыла. Төче су запаслары кимегәннән-кими бара. Сулыкларны пычрату да төче су запасының кимүенә китерә. Бу, үз чиратында, кешелекнең җирдә яшәвенә куркыныч тудыра. Шуңа күрә чишмәләрне, су чыганакларын карап, чистартып торуны һәр кеше үзенең бурычы итеп карарга тиеш. Без елга-күлләрне, сулыкларны пычрату белән даими очрашабыз.

Бу хәл безне борчырга, табигатьнең бу кадерле бүләгенә игътибарлы булырга чакырырга тиеш.

эчергә яраклы су – вода, пригодная для питья//питьевая вода

төче су – пресная вода

тозлы су – соленая вода

кими бара – становится меньше//уменьшается

су тотыла – вода расходуется // вода тратится

бик аз проценты- очень малый процент

яшәү өчен – для жизни

әһәмиятле - важный

7. **Какой послелог нельзя использовать в предложении? По 1 баллу за каждый правильный ответ, макс. б.-3**

А. Мәктәпкә Айдардан ... кеше килмәде.
1) башка 3) бүтән
2) тыш <u>4) белән</u>
Ә. Илдар сөт ... ак күгәрчен күрде.
1) кебек 3) тикле
<u>2) өчен</u> 4)сыман
Б. Башта урманга ... бар**.**
<u>1) саен</u> 3)тикле
2) кадәр 4)хәтле

**4. Прочитайте текст. Преобразуйте слова, написанные заглавными буквами в конце строк, чтобы они грамматически соответствовали содержанию текста, по 2 балла, макс. б. – 16.**

| | |
|---|---|
| ЕЛНЫҢ иң соңгы ае – декабрь. | ЕЛ |
| Декабрь елны тәмамлый, КЫШНЫ башлый. | КЫШ |
| ЕЛГАЛАРДА, күлләрдә боз калыная. Кышкы боз ышанычлы. | ЕЛГА |
| Боз ӨСТЕНДӘ балыкчылар утыралар. | ӨС |
| Алар боз астыннан балык ТОТАЛАР . | ТОТАРГА |
| Декабрьдә чуртан, алабуга ЭЛӘГӘ . | ЭЛӘГЕРГӘ |
| Балыклар һава ТОРЫШЫНА бик сизгер . | ТОРЫШ |
| Көчле суыкларда һәм салкын ҖИЛЛЕ көндә балык аз эләгә. | ҖИЛ |

**5. В какой последовательности необходимо поставить выражения, чтобы получилось предложение? (4 б.)**

А) акыл табылмас
Ә) акыл белән
Б) алтын табылса да
В) алтын белән

<u>1) Ә, Б, В, А</u> 2) Б, А, В, Ә 3) А, В, Б, Ә 4) Б, Ә, А, В

**6. Переведи на татарский язык и запиши (по 3 б., макс.б.- 21).**

**1.**Когда-то ветер, вода и правда были друзьями. **2.** И однажды правда и вода спросили у ветра: “ Скажи, друг, вот ты очень быстрый и бродишь по всему миру, скажи, когда понадобишься, где тебе найти?” **3. “**Вы найдете меня между гор”. **4.** Тогда ветер и правда спросили у воды, где ее найти в нужный момент. 5**.** “Вы найдете меня в фонтанах, реках и океанах”, -

сказала вода. 6. И в конце вода и ветер спросили у правды: “ Где тебя, правда, найти в нужный момент?” 7. А она ответила: “Я должна быть всегда среди людей, ищите среди людей”.

| № | **Предложения** | **Баллы** (макс.) ( 21 ) | **Сумма** (фактич.) (    ) |
|---|---|---|---|
| 1. | Кайчандыр җил, су һәм дөреслек дуслар булганнар. | **3** | |
| 2. | Бервакыт дөреслек һәм су җилдән сораганнар: “ Дускай, әйт әле, син бик җитез (тиз) һәм бөтен дөнья буйлап йөрисең, кирәк булганда, сине кайдан табарга була?” | **3** | |
| 3. | “Сез мине таулар арасында табарсыз”. | **3** | |
| 4. | Инде җил белән дөреслек судан сораганнар, кирәк вакытта кайдан табып була дип. | **3** | |
| 5. | “ Сез мине фонтаннарда, елгаларда, океаннарда табарсыз”, - дигән су. | **3** | |
| 6. | Инде су һәм җил дөреслектән сораганнар “Дөреслек, кирәк вакытта сине кайдан табып була?” | **3** | |
| 7. | 2Мин һәрвакыт кешеләр арасында булырга тиеш, кешеләр арасыннан эзләгез”, - дигән ул. | **3** | |

**7. Напиши подходящие реплики (по 3 б., макс.б . -15)**

**1.** Спроси у друга (подруги), какую книгу он (она) взял(а) в библиотеке.

2.Сообщите учителю, что Вы следующую неделю уезжаете на экологическую конференцию..

3. Сообщите другу (подруге), если в выходные погода будет хорошая, то вы всей семьей пойдете на каток.

4. Спросите у брата, какие события происходят в мире.

5. Напомни брату, что послезавтра у бабушки день рождение

| № | Предложения | Баллы (макс.) ( 15) | Сумма (фактич.) ( ) |
|---|---|---|---|
| 1. | - Дустым, син китапханәдән нинди китап алдың? | 3 | |
| 2. | - Гүзәл Илдаровна, мин киләсе атнада экология конференциясенә китәм | 3 | |
| 3. | - Дустым, ял көннәрендә һава торышы (көннәр) яхшы булса, без гаиләбез белән шугалакка барабыз. | 3 | |
| 4. | - Абый, дөньяда ниләр бар? | 3 | |
| 5. | - Абый, берсекөнгә әбинең туган көне. | 3 | |

8. **По тексту составьте диалог на татарском языке (8 реплик). (16 баллов, по 2 балла за каждое правильное предложение).**

Изге күңелле, олы йөрәкле Әсгать абый турында газета-журналларда күп язылды. Одесса киностудиясе нәфис фильм төшерде. Хәтта Америка журналистлары да, килеп, аның белән танышып китте. Әсгать Галимҗанов шундый игътибарга ничек лаек булды соң? Мин бу сорауга эшчән һәм игелекле кеше булуы белән дип җавап бирер идем.

Аның игелекле эшләрен санап кына бетерерлек түгел. Грузиядә һәлакәт булганнан соң, аларга ярдәм итә. Әрмәнстанга, Иваново шәһәрендәге интернат-мәктәпкә акча җибәрә. Чернобыль атом электр станциясендә зыян күрүчеләргә дә булыша. Казан шәһәрендәге балалар йортларын җиһаз, кием, дистәләрчә автобус белән тәэмин итеп тора.

- Әсгать абый нинди кеше?
- Ул изге күңелле, олы йөрәкле кеше.
- Аның турында материаллар кайдан алып була?
- Әсгать абый турында газета-журналларда күп язылды. Одесса киностудиясе нәфис фильм төшерде.

....____________________________________________________________

______________________________________________________________

______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
___________________________________________________________

**9. Впиши начало предложений (по 3б., макс.б. – 15).**

1. ... , мин анда бара алмыйм. 2. ... , син барырга тиеш идең. 3. ... мәктәптән соң алар еш паркка бара иделәр. 4. ... , аның сиңа шәһәрне күрсәтәсе килә. 5. ..., малайлар тиз генә чишенеп, суга сикерделәр.

| № | **Предложения** | **Баллы** (макс.) (15 ) | **Сумма** (фактич.) ( ) |
|---|---|---|---|
| 1. | Авырып китүем сәбәпле, ... | **3** | |
| 2. | Бүген мәктәптә җыелыш булды, ... | **3** | |
| 3. | Күзге матур көннәрдә ... | **3** | |
| 4. | Иртәрәк кайтырга тырыш, ... | **3** | |
| 5. | Елга буена килеп җитүгә,... | **3** | |